**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«11» 06 2025 ел Яр Чаллы ш. № 1909

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру турында» 2024 елның 19 ноябрендәге 5189 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Укучыларны балансланган кайнар аш белән тәэмин итү нормаларын үтәү, аларның сәламәтлеген саклау, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрү максатында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ Федераль закон нигезендә, «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.3/2.4.3590-20 таләпләрен үтәп, «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар тукландыруны оештыруга норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар тукландыруның уртача бәясенраслау турында» 2025 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 апрелендәге 253 номерлы карарына таянып, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясенә үзгәреш кертү турында» 2025 елның 27 маендагы 362 номерлы карарына таянып, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру өчен, Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 20 октябрендәге 3163 номерлы, 2022 елның 20 декабрендәге 4110 номерлы, 2025 елны елның 7 майдагы 1491 номерлы карарларын үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясы 7.2 өлеше, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы 6.1 өлеше нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Башкарма комитетның 2024 елның 19 ноябрендәге 5189 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныф укучылары өчен көненә кайнар аш бәясен 80 сум 30 тиен күләмендә;»

2.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Айлык акчалата түләүләр бәясен:

- «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясенә үзгәреш кертү турында» 2025 елның 27 маендагы 362 номерлы карары нигезендә уку чорында бер укучыга бер көнгә 10 сум 30 тиен;»

2.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусындагы инвалид балаларга, шул исәптән өйдә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны иректә үтәүче гражданнарның, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләренең балаларына, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән категория гражданнарының балаларына бер көнгә бер укучыга ике тапкыр туклану нормасын билгеләргә:

- 1дән 4 сыйныфка кадәр: иртәнге аш– 10 сум 30 тиен, төшке аш – 74 сум 77 тиен;

- 5тән 11 сыйныфка кадәр: иртәнге аш – 10 сум 30 тиен, төшке аш 80 сум 30 тиен.»

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының финанс бюджет палатасына гомуми белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә каралган акчаларны үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә 3 эш көне эчендә әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев